ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
.
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.12.2024 Мөслим ав. № 550

**«Мөслим муниципаль районы территориясендә инвалидлар яши торган күпфатирлы йортларда инвалидларның торак урыннарын һәм гомуми мөлкәтне тикшерү буенча муниципаль комиссия төзү турында» Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 1 ноябрендәге 397 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 09 июлендәге 649 номерлы «Инвалидлар ихтыяҗларын исәпкә алып, күпфатирлы йортта торак урыннарны һәм гомуми мөлкәтне урнаштыру чаралары турында» карары нигезендә һәм махсус хәрби операцияда катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм мәсьәләләре буенча Региональ ведомствоара комиссия утырышының 2024 елның 03 декабрендәге ЛФ-12-345 номерлы беркетмәсе нигезендә, Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Мөслим муниципаль районы территориясендә инвалидлар яши торган күпфатирлы йортларда инвалидларның торак урыннарын һәм гомуми мөлкәтне тикшерү буенча муниципаль комиссия төзү турында» Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 01 декабрендәге 397 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә, 1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә.
2. «Мөслим муниципаль районы территориясендә инвалидлар яши торган күпфатирлы йортларда инвалидларның торак урыннарын һәм гомуми мөлкәтен тикшерү буенча муниципаль комиссия төзү турында» Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының 397 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 18 апрелендәге 183 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Ф. Салихҗанов**

Мөслим муниципаль районы
Башкарма комитетының
«12» 12 2024 елның 550 нче
номерлы карарына 1 нче кушымта

**Мөслим муниципаль районы территориясендә инвалидлар яши торган күпфатирлы йортларда инвалидларның торак урыннарын һәм гомуми мөлкәтне тикшерү буенча муниципаль комиссиянең**
**ПЕРСОНАЛ СОСТАВЫ**

| | |
|---|---|
| Салихҗанов И.Ф. | Башкарма комитет җитәкчесе, комиссия рәисе; |
| Мөхәммәтдинов Д.З. | Инфраструктур үсеш буенча Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары, комиссия рәисе урынбасары; |
| Иванова Л.Р. | Инфраструктура үсеше бүлегенең баш белгече комиссия секретаре; |

**Комиссия әгъзалары:**

| | |
|---|---|
| Сәйфиев И.Ф. | Инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы; |
| Фәтхуллина Г.Р. | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Мөслим муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Фәхерлегаянова Г.Ф. | «Мөслим» ИК ЖЧЖ директоры (килешү буенча); |
| Низамов И.Х. | Мөслим муниципаль районының ветераннар (пенсионерлар) советы рәисе. |
| Шәяхмәтова А. Р. | «Ватанны саклаучылар» махсус хәрби операциясендә катнашучыларга ярдәм итү дәүләт фондының Татарстан Республикасы буенча филиалы вәкиле-инвалидлар белән эшләү секторының социаль координаторы (килешү буенча). |
| Хафизов И.И. | «Мир, доступный для всех» ВОИ СДС эксперты (килешү буенча). |
| А.Р. Яббарова | Мөслим районында Ватанны саклаучылар Дәүләт фондының социаль координаторы ярдәмчесе. |